# “Бакырчы башлангыч мәктәп – балалар бакчасы” муниципаль бюджет белем учреждениесенең эшчәнлеге турында киң җәмәгатьчелек өчен доклады

2016 ел

## КЕРЕШ

Бу доклад учреждениедә башкарылган эшчәнлек, аның нәтиҗәсе, эш барышында килеп туган авырлыклар һәм белем бирү учреждениесенең алга таба үсешендә төп мәгълүматны туплаган. Без сезне учреждениедәге традицияләр, укыту шартлары, укыту программалары һәм узган уку елына учреждениенең эш нәтиҗәләре белән таныштырырбыз.

Бу доклад белән балалар да, ата-аналар да, Мәгариф идарәсе дә, гомумән, бу елларда кемнәр безнең эшчәнлеккә ярдәм иткән, кемнәр безнең учреждение турында белергә тели - барысы да таныша алалар.

## ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА

*Безнең визит карточкабыз*

*Тулы исеме:* "Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бакырчы башлангыч мәктәп – балалар бакчасы" муниципаль бюджет белем учреждениесе.

*Географик урыны:* безнең учреждение Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Акъегет авылы җирлегендә урнашкан. Авылыбыз район үзәгеннән 100 км ераклыкта урнашкан. Район үзәгенә поезд һәм автобус юллары белән барырга мөмкин.

*Авылның демографик хәле:* Бакырчы авылында 357 кеше яши, шуларның 36 се 14 яшькә кадәр балалар, 16ы 18 яшькә кадәр.

Бакырчы башлангыч мәктәп – балалар бакчасы муниципаль бюджет белем учреждениесе түбәндәге адрес буенча урнашкан: 422535, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Бакырчы авылы, Советская урамы, 18 йорт . Гомуми мәйданы 2900 кв.м. Җир участогы 0,60 га. Мәктәбебезне яфраклы агачлар, куаклар, чәчәк түтәлләре бизәп тора. Бакчада яшелчә һәм җиләк-җимешләр үстерелә. 1 спорт һәм 1 уен мәйданчыгы бар.

Учреждение 1983 елда төзелгән һәм 1991 елда 1870 елны тәзелгән бай йортын сүтеп бергә кушып эшләгән элеккеге төп белем мәктәбе бинасында урнашкан. Бер дә капиталь ремонт үткәрелмәгән. Реконструкция нәтиҗәсендә мәктәп башлангыч сыйныфларга калдырылды һәм бинага балалар бакчасы күчерелде. Мәктәптә 2 башлангыч сыйныфлар кабинеты, укучылар өчен аш бүлмәсе; ә балалар бакчасы өчен уен, йокы бүлмәләре, санузел, кер юу бүлмәсе, коридорда чишенү урыны булдырылды. Канализация үткәрелде, азыкларны саклау һәм ашарга әзерләү бүлмәләре яңартылды; шулай ук директор кабинеты, методик кабинет, китапханә бүлмәсе, музей бар. Укучыларга 2012 елны парталар, ашханә өчен 2013 елны холодильник, электр плитәсе, керләр юу өчен керюу машинасы кайтарылды.

Бу уку елында учреждениедәге җиһазлар яңартылмады. Мәктәпнең тирә-ягы каралды, тимер баганалар утыртылып сетка тотылды.

***Телефон, факс***: 8(84371) 2-53-04, факс юк.

***Электрон почта адресы***: **sch1309@yandex.ru**

*Директор:Сафиуллин Җәүдәт Тәлгать улы.*

*Безнең максатыбыз:* балаларны әхлакый яктан өлгергән, культуралы, иҗади актив, белемле һәм тормышка әзерлекле шәхес итеп тәрбияләү.

*Учреждение турында кыскача белешмә:* Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитетының 2012 елының 12 сентябрендә чыккан 2220 номерлы карары нигезендә “Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бакырчы башлангыч мәктәп – балалар бакчасы” муниципаль бюджет белем учреждениесе барлыкка килде. Безнең белем учреждениесендә 1,5 яшьтән алып 10 яшькә кадәр балалар тәрбия һәм белем алалар.

Уку елы озынлыгы - 34 атна (беренче сыйныф укучылары өчен - 33 атна), 1 класста дәрес озынлыгы- 35 минут, 2,3,4 класста дәрес озынлыгы – 45 минут. Башлангыч мәктәптә 2 класс-комплект, анда - 9 укучы белем ала, балалар бакчасында төрле яшьтәге 12 бала тәрбияләнә. 1 сыйныфлар 5 көнлек, 2-4 сыйныфлар 6 көнлек уку атнасы буенча белем алалар. Балалар бакчасы 5 көн дәвамында 9 сәгатьлек эш режимы белән шөгыльләнәләр. Балалар бакчасында дәресләр озынлыгы: мәктәпкә әзерлек төркемендә – 35 минут, зурлар төркемендә – 25 минут, уртанчылар төркемендә – 20 минут, 2 кечкенәләр төркемендә – 15 минут, 1 кечкенәләр төркемендә – 10 минут.

***Таблица №1.*** *Укучылар һәм тәрбияләнүчеләр турында өч еллык гомуми белешмә*

| Статистика буенча кеше саны | 2013-2014 уку елы. | 2014-2015 уку елы. | 2015-2016 уку елы. |
|---|---|---|---|
| 1. Барлыгы | 19 | 22 | 22 |
| • балалар бакчасында | 9 | 10 | 9 |
| • башлангыч мәктәптә | 10 | 12 | 12 |
| 2. Икенче уку елына калдырылган | - | - | - |
| 3. Шартлы рәвештә күчерелгән | - | - | - |
| 4. Уку алдынгылары (бишле билгеләренә генә өлгерүчеләр) | 1 | - | - |

*Педагогик коллектив:* Бакырчы башлангыч мәктәп – балалар бакчасында иҗади эшләүче педагоглар коллективы тупланган. Бездә барлыгы 5 педагог эшли: 3 укытучы, 1 директор , 1 тәрбияче. Коллективның уртача яшь озынлыгы – 45 яшь. 4 педагог югары белемле, урта махсус белем белән 1 педагог эшли. Уртача педагогик стаж – 20 ел. Беренче квалификацион категорияле 3 педагог, икенче квалификацион категорияле – 2 педагог.

Эшләүче педагоглар даими рәвештә квалификацияне күтәрү курсларында белем алалар. Алар үз эшләрендә яңа технологияләрне уңышлы кулланалар, үз белемнәрен күтәрү өстендә даими эш алып баралар. Педагоглар район һәм республика күләмендә үткәрелә торган семинарлар, киңәшмәләрдә катнашалар, чыгышлар ясыйлар.

*Мәктәп күләмендә үткәрелә торган чаралар:*

- белемгә уңай караш тәрбияләү максатыннан Белем көне;
- Өлкәннәр көне – олыларга карата мәхәббәт һәм хөрмәт хисе тәрбияләү;
- “Көзге бал”- көзге табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтү;көзге уңышны җыюда катнашу, аларны җыр-биюләр,инсценировка аша күрсәтү.
- Укытучылар һәм Тәрбиячеләр көне;
- Аналар көне – әниләргә хөрмәт хисе тәрбияләү;
- балаларның иҗади сәләтен үстерү максатыннан Яңа ел бәйрәме;
- спорт бәйрәмнәре һәм спорт ярышлары балаларда спорт белән кызыксыну һәм спорт төрләре белән шөгыльләнергә омтылыш тәрбияләү максатын күздә тота;
- Әлифба бәйрәме;
- Сәламәтлек көннәре –сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү;
- Ватанны саклаучылар көне – патриотик тәрбия;
- Туган тел көне – туган телгә мәхәббәт тәрбияләү;
- “Могҗизалар кыры” уенын үткәрү;
- Халыкара хатын-кызлар көне – әхлак тәрбиясе;
- Нәүрүз бәйрәме – халкыбызның милли традицияләре һәм гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү;
- Тукай көннәре атналыгы – әдәбият белән кызыксыну тәрбияләү;
- Экология атналыгы – табигатькә мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү;
- Кошларны каршы алу.
- Җиңү көне – үткәннәрне истә тоту һәм ветераннарга ихтирам тәрбияләү;
- башлангыч сыйныфлар һәм балалар бакчасы белән саубуллашу бәйрәме;
- Балалар сабан туе – балаларның иҗади сәләтен үстерү максатыннан үткәрелә.

*Безнең соңгы еллардагы уңышларыбыз:*

- безнең укучыларыбыз даими рәвештә математика фәненнән «Кенгуру» халыкара уен-конкурсында,
- Россия күләмендә үткәрелә торган «Русский медвежонок», «Английский бульдог» уен - конкурсларында;
- татар теленнән «Зирәк тиен» региональ конкурсында;
- төрле фәннәр буенча үткәрелә торган олимпиадаларда;
- балалар иҗатына багышланган район күләмендәге иҗади конкурсларда

катнашып киләләр.

## ТАРИХИ СПРАВКА

Безнең Яшел Үзән районының (элекке Зөя өязе) Бакырчы авылы – борынгы авыл.

1890 еллардан соң авылыбызда 2 мәчет, 2 мәхәллә булган. Бөек Октябрь социалистик революциясенән соң тагын бер яңа мәдрәсә ачылган.

1931 елда заманында атаклы бай булган Миңнебай йортында дүртьеллык башлангыч мәктәп оеша һәм ул 60 ел дәвамында яшь буынга белем һәм тәрбия бирү хезмәтен башкара.

1991 елны авылыбызда "Бакырчы" колхозы рәисе Зәбиров З.З., мәктәп директоры Исмәгыйлев Х.З. һәм ата-аналарның тырышлыгы белән 9 еллык мәктәпкә яраклаштырылган бина төзеп, төп гомуми белем бирү мәктәбе ачу бәхетенә ирешелә.

### Бакырчы мәктәбенең үсеш этаплары:

**1931 - 1990 елларда** Бакырчы башлангыч мәктәбе

1931 елда Бакырчы башлангыч мәктәп оешуы хакында документлар сакланмаган.

**1991 – 1997 елларда** Бакырчы тулы булмаган урта мәктәп

1990 елда Бакырчы башлангыч мәктәбенең Бакырчы тулы булмаган урта мәктәбенә үзгәртелүе хакында документлар (Решение Президиума Зеленодольского Районного Совета Народных Депутатов ТССР №250 от 29.05.1991 год.)

**1997 – 2007 елларда** Татарстан Республикасы Зеленодол районы "Бакырчы Төп гомуми белем мәктәбе" коммуналь белем учреждениесе /Татарстан Республикасы Зеленодол районы һәм Зеленодольск шәһәре администрациясе башлыгы карары/

**2003 – 2007 елларда** Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы "Бакырчы төп гомуми белем мәктәбе" дәүләт белем учреждениесе /Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының Яшел Үзән мәгариф бүлеге Советы карары - №34, 13.02.2003/

**2007 - 2011 елларда** “Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Бакырчы төп гомуми белем мәктәбе” муниципаль белем учреждениесе / Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Башкарма комитеты карары - №437, 09.04.2007 /

**2011 елдан** “Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Бакырчы башлангыч мәктәп” муниципаль бюджет белем учреждениесе / Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Башкарма комитеты карары - №1055, 01.17.2011 /

**2012 елдан** “Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Бакырчы башлангыч мәктәп – балалар бакчасы” муниципаль бюджет белем учреждениесе / Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Башкарма комитеты карары - №2220, 18.09.2012 /

## БҮГЕНГЕ ЯШӘЕШЕБЕЗ

***Таблица №2. Ата-аналарның белем дәрәҗәсе (2016 ел өчен)***

| | |
|---|---|
| Югары уку йортын тәмамлаучылар (югары белемле ) | 4 |
| Һөнәри техникум, колледж тәмамлаучылар (махсус урта белемле) | |
| Һөнәри училище тәмамлаучылар (башлангыч һөнәри белемле) | 9 |
| Урта белемле | - |
| Тулы булмаган урта белем | - |

***Таблица №3. Ата-аналарның эш белән тәэмин ителүе (2016 ел)***

| | |
|---|---|
| Хезмәткәрләр | 7 |
| Эшмәкәрләр | |
| Эшчеләр (сезонлы эшләрне исәпкә алып) | 6 |
| Эшсезләр | - |

***Таблица №4. Балаларның гаилә хәле (2016 ел)***

| Критериеләр | Мәктәпкәчә тәрбия төркеме | Башлангыч мәктәп | Барлыгы |
|---|---|---|---|
| Барлык бала саны | 12 | 9 | 21 |
| Шуларның | | | |
| Тулы гаилә | 10 | 9 | 19 |
| Тулы булмаган гаилә | 2 | - | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Күп балалы гаилә | 3 | 6 | 9 |
| Авыр гаиләләр | - | - | - |
| Баланы тәрбиягә алучы гаилә | - | - | - |

***Таблица №5  Ата-аналарның балаларның укуы белән кызыксынучанлыгы (2016 ел)***

| | |
|---|---|
| Балаларның белем алуы белән кызыксыналар | 100% |
| Балаларның белем алуы белән кызыксынмыйлар | 0% |

***Таблица №6. Ата-аналарның мәктәп белән берлектә эшләүләре (2016 ел)***

| | |
|---|---|
| Мәктәп белән берлектә эшлиләр | 100% |
| Мәктәп белән берлектә эшләргә теләмиләр | 0% |

***Таблица №7. Укучылар санындагы үзгәрешләр***

| Укучылар саны | 2014/2015 уку елы | 2015/2016 уку елы | 2016/2017 уку елы |
|---|---|---|---|
| Ел башында | 10 | 12 | 9 |
| 1 сыйныф | 2 | 4 | 1 |
| Китүчеләр | - | - | - |
| Килүчеләр | - | - | - |
| Куылучылар | – | – | – |
| Уку елы ахырында | 10 | 12 | 9 |

Алдагы еллар өчен күрсәткечләргә карасак, укучылар саны һәм 1 сыйныфка алынучылар саны 3 балага кимеде.(сәбәбе.....)

2016-2017 уку елында, башка еллардагы кебек үк, авыл җирлегендә яшәүче, 1 сыйныфка керергә тиешле барлык балалар да укырга керделәр.

Китүче семьяларны исәкә алмасак.

***Таблица №8 2016-2017 уку елында укучылар һәм балалар саны***

| Белем алу баскычлары | Төркем һәм класс-комплект саны | Балалар һәм укучылар саны | |
|---|---|---|---|
| | | Уку елы башында | Уку елы ахырында |
| Балалар бакчасы | 1 | 13 | 12 |
| Башлангыч мәктәп | 2 | 9 | 9 |
| Барлыгы | 3 | 22 | 21 |

## БАЛАЛАРНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕГЕ ҺӘМ ТУКЛАНУНЫ ОЕШТЫРУ

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, укучылар һәм балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр арасында авыру балалар саны елдан ел арта бара. Балаларның сәламәтлегенә зыян салучы факторлар да күбәя:теле- радио антенналар, компьютер, телевидение, әйләнә-тирә мохитның пычрануы, көндәлек режимның үтәлмәве, витаминнар җитмәү, мәктәптә башкарыла торган эшнең күләме, аз хәрәкәтләнү һ.б. Балалар арасындагы авыру очракларын анализлау педагогларга балалар һәм ата-аналар белән эшләү юнәлешләрен билгеләү өчен кирәк. Ә бу үз чиратында, мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларның авыруларын киметү өчен эшләнелә.

Балаларга уңай шартлар тудыру өчен без: дәресләр челтәрен СаНПиН таләпләренә туры китереп төзибез, дәресләрдә физкультминуткалар, күзләр өчен күнегүләр үткәрелә, балалар рәтләр буенча утыртылган, Сәламәтлек көннәре, спорт ярышлары үткәрелә, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өстендә зур эш алып барыла. Мәктәпкәчә яшьтәге һәм укучы балалар өчен чыгарылган җиһазлар нормативы саклана, куркынычсызлык кагыйдәләре буенча инструктажлар үткәрелә. Бездә балалар һәм хезмәткәрләрнең имгәнү очраклары теркәлмәгән.

Мәктәптә балалар кайнар аш белән тәэмин ителгән, тукланучы балалар саны – 100%. Ашау 9.24 сум, мәктәп бакчасында җитештерелгән яшелчәләрне куллану – 2.74 сум, компенсация – 6.50 сум. (Ата-аналар белән уздырылган анкета нигезендә 6.50 сумны барлык балаларга да бирү мәсьәләсе)

Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр көнгә 3 тапкыр тукла624налар: иртәнге аш, төшке аш, кичке әбәт (полдник). Азыкны витаминнарга баету да күздә тотыла (С витамины белән баетылган чәй, салатлар, соклар, җиләк-җимеш, йодлаштырылган тоз кулланыла).

Учреждениедә азык-төлекне саклау һәм ашарга әзерләү бүлеге бар, 1- 4 сыйныф балаларын ашханәдә оештырылган, балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр үз бүлмәләрендә туклана624лар.

Ашханәдәге меню төрләндерелә. Әзерләнгән азыкның куллану вакыты, сыйфаты көндәлек тикшерелеп барыла һәм махсус журналда теркәлә. Тикшерүчеләр тарафыннан ашханә эшчәнлегенә кагылышлы кисәтүләр ясалмады.

## БАЛАЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

**Социаль паспорт**

| | |
|---|---|
| 1- 4 сыйныф укучылары саны: | 9 |
| - кызлар | 5 |
| - малайлар | 4 |
| Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр саны: | 12 |

- кызлар 7
- малайлар 5

Күп балалы гаиләләр 8

Аз керемле гаиләләр 3

Тулы булмаган гаиләләр 1(Камалиевлар)


Сәләтле балалар саны 12

**Ата – аналар турында белешмә**

| Хезмәткәрләр | Эшчеләр | Эшсезләр | Югары белемле | Тулы булмаган югары белемле | Махсус урта белемле | Урта белемле | Тулы булмаган урта белемле |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **7** | **6** | **-** | **4** | | **9** | **-** | **-** |

Барлык ата-аналар : 15 **кеше**

**БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕН ИДАРӘ ИТҮ ТӨЗЕЛЕШЕ**






Белем бирү учреждениесенең эш юнәлешләре:

- укыту-методик;
- тәрбия эше;
- административ-хуҗалык;
- куркынычсызлык;

Бөтен юнәлешләрнең эшчәнлеге Устав нигезендә алып барыла. Административ җитәкчелекне директор башкара. Директорның төп вазифасы - укыту һәм тәрбия эшендә катнашучыларны бергә туплап куелган максатларга ирешүне булдыру. Идарә итүнең иң югары органы булып педсовет һәм Ата-аналарның гомуми җыелышы тора. Педсовет һәм Ата-аналар җыелышына Белем учреждение Советы күзәтчелек итә.

## УКУ-УКЫТУ ЭШЧӘНЛЕГЕН АЛЫП БАРУ ШАРТЛАРЫ

### Материаль-техник база

Белем бирү учреждениесендә уку-укыту эшчәнлеген алып бару өчен барлык кирәкле шартлар да тудырылган диярлек: кабинетлар, балалар уйнау өчен мәйданчык һәм спорт мәйданчыгы бар.

Учреждение компьютерлар, проектор, магнитофоннар, телевизор-2 шт), DVD, ксерокс, сканер һәм башка техник средстволар белән җиһазландырылган. Компьютерлар Интернет челтәренә тоташтырылган, мәктәп сайты уңышлы эшләп килә. Учреждениедә үзәкләштерелгән белем бирү ресурслары коллекциясе: төрле фәннәр буенча диск һәм аудиокассеталар тупланган. Мәктәп укучылары кирәкле дәреслекләр, педагоглар укыту программалары һәм дидактик материаллар белән тәэмин ителгән. Мәктәптә педагоглар тулысынча электрон журналлар белән генә эшлиләр, укучылар электрон көндәлекләрдән файдаланалар.

### Учреждениенең укыту планы. Эш режимы.

Муниципаль белем учреждениесе белем бирүдә даимичәнлек һәм дәвамчанлык принципларына нигезләнеп эшли. Мәктәптә балалар 1-4

сыйныфлар “Перспектива” программалары буенча белем ала, балалар бакчасындагы тәрбияләнүчеләр М.А.Васильева программасы буенча шөгыльләнәләр. Бу программалар Россия Федерациясенең Мәгариф турындагы законы нигезендә сайлап алынган. Уку-укыту планы белем бирүнең дәүләт стандартларының федераль компоненты БУП – 2016 нигезендә төзелде. (МОиН РТ хаты нигезендә)

Укытуның төп формасы булып сыйныф-дәрес системасы тора.

Укыту планын төзегәндә сыйныфлар арасындагы дәвамчанлык, фәннәр арасындагы бәйләнеш саклanды. Укучылар өчен атналык эш күләме тиешле дәрәҗәдән артмады.

1 – 4 сыйныфлар өчен төзелгән укыту планы балаларга дүртьеллык башлангыч белем алуга юнәлдерелгән.

Эш режимы: Устав нигезендә 1 сыйныфлар 5 көнлек уку атнасы, 2-4 сыйныфлар 6 көнлек уку атнасы буенча белем алалар. Санитарно-эпидемиологик кагыйдәләр буенча 1 сыйныфлар өчен 5 көнлек уку атнасы вакытында атнага 20 дәрес һәм дәресләр озынлыгы беренче яртыеллыкта 35 минут, ә икенче яртыеллыкта 45 минут, 2-4 сыйныфлар өчен 6 көнлек уку атнасы вакытында атнага 25 дәрес һәм дәресләр озынлыгы 45 минут. Шул ук вакытта дәүләт стандартларың федераль компонентында һәр фән өчен каралган сәгатьләр саны һәм укыту эчтәлеге тулысынча саклана.

Укыту түләүсез, бер сменада алып барыла. Дәресләр 8.30. сәгатьтә башлана. Каникуллар уку елы дәвамында 30 календарь көн, 1 сыйныфлар өчен февраль аенда бер атналык өстәмә каникул каралган.

Дәрестән тыш һәм сыйныфтан тыш эшчәнлек шәхеснең үсешен, фәннәр буенча белемнәрне тирәнәйтүне күздә тота. Дәрестән тыш эшчәнлек түбәндәге юнәлешләр буенча оештырылды: “Сәламәт булып үс” – сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү, “Туган телем – иркә гөлем” – гомуми интеллектуаль үсеш.

Балалар бакчасында да, мәктәптә дә дәресләрдә балаларга фәннәр буенча тирәнтен белем бирү, логик фикерләүләрен үстерү, сөйләм һәм аралашу культурасын тәрбияләү өстендә эш алып барыла.

Укыту планы түбәндәге эш нәтиҗәләрен максат итеп куя:

- балалар һәм ата-аналарның белем алуга карата теләкләрен канәгатьләндерү;
- белем һәм күнекмәләрнең сыйфатын күтәрү;
- балаларның иҗади сәләтләрен үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру;
- укытуда дәвамчанлыкны саклау.

**2016-2017 уку елына**
**1-4 сыйныфлар өчен укыту планы**
**(укыту татар телендә барганда)**

| Уку фәннәре | | Сыйныфлар | | |
|---|---|---|---|---|
| | **1** | **2** | **3** | **4** |
| | Атнага сәгать саны | | | |
| Рус теле | 3 | 4 | 3 | 3 |
| Әдәби уку (рус) | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Татар теле | 3 | 3 | 4 | 3 |
| Әдәби уку (тат) | 1 | 2 | 2 | 3 |
| Чит тел (инглиз) | - | 2 | 2 | 2 |
| Математика | 4 | 4 | 4 | 4 |
| Әйләнә-тирә һәм ТИН | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Сәнгать (музыка и сынлы сәнг.) | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Технология (хезмәт) | 1 | 1 | 1 | 1 |
| Физ культура | 3 | 3 | 3 | 3 |
| Дин тарихы (ОРКСЭ) | - | - | - | 1 |
| Барлыгы | 21 | 25 | 25 | 26 |
| Белем учреждениесе компоненты (6 көнлек уку атнасы)<br>Рус теле<br>Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәният нигезләре | - | 1 | 1 | - |
| 5 көнлек укыту атнасында каралган эш күләме | - | - | - | - |
| 6 көнлек укыту атнасында каралган эш күләме | 21 | 26 | 26 | 26 |

Башлангыч белем программаларын сыйфатлы үзләштерү максатыннан мәктәп компоненты сәгатьләре 3 сыйныфта рус теле, 2 сыйныфта татар теле, 4 сыйныфта (ата-аналар ризалыгы нигезендә) Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәният нигезләре фәненә бирелде.

Чит тел (инглиз теле) 2 сыйныфтан укытыла.1 класста танышу нигезендә алып барыла. Әлеге фән буенча материалны үзләштерү өчен укыту планындагы сәгатьләр саны тиешле күләмдә бирелгән.

“Әйләнә-тирә дөнья” фәнен өйрәнүгә 1 сыйныфта атнага 2 сәгать, 2-4 сыйныфларда 2 сәгать бирелгән. Бу катнаш фән. Аның эчтәлегенә үстерешле модульләр, социаль-гуманитар юнәлеш һәм иминлек кагыйдәләре элементлары кергән.

Компьютер буенча белемнәрен арттыру максатыннан «Технология (хезмәт)» фәне эченә «Информатика һәм информацион-коммуникатив технологияләр (ИКТ)» модуле кертелгән.

Балаларда сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү программасын үтәү йөзеннән “Сәламәт булып үс” дип аталган дәрестән тыш эшчәнлек алып барыла, физкультура дәресләре файдаланыла, саф һавада уеннар оештырыла, дәресләрдә физкультминуткалар үткәрелә. Балаларның иминлеген саклау сыйныф сәгатьләрендә һәм әйләнә-тирә дөнья фәне дәресләрендә аңлатыла.

Укыту планын тормышка ашыру өчен учреждение тиешле кадрлар, методик ярдәмлек, материаль-техник база белән тәэмин ителгән.

## Балалар бакчасында укыту эшчәнлеге

Балалар бакчасында уку-укыту эшчәнлеге “Туганнан алып мәктәпкәчә” программасы нигезендә алып барыла. Бу программа балаларның 7 яшькәчә чорында тәрбия һәм белем бирүнең барлык төп юнәлешләрен чагылдыручы программа булып тора. Балалар бакчасында иң гади математик күзаллауны формалаштыру, әдәби әсәрләр, милли уеннар, гореф-гадәтләр белән таныштыру, физик тәрбия - сәламәтләндерү, сөйләм үстерү, рус теле, әйләнә-тирә дөнья, грамота нигезләрен үзләштерү, музыкаль сәнгатъ эшчәнлеге, экологик тәрбия, иҗади сәнгать эшчәнлеге: рәсем, әвәләү, кисеп ябыштыру буенча шөгыльләр үткәрелә.

Дәресләр челтәре балалар бакчасында СанПин 2.4.1.2660-10 нормаларына нигезләнеп төзелә.

2 кечкенәләр төркемендә шөгыль дәвамлыгы 15 минут, шөгыльләр арасында 10 минутлык ял уздырыла. Көн дәвамында 2 шөгыль, атнага бер тапкыр 3 шөгыль каралган - физик тәрбия саф һавада үткәрелә.

Уртанчылар төркемендә шөгыль озынлыгы - 20 минут, шөгыльләр арасында 10 минутлык ял. Көн дәвамында 3 шөгыль, атнага бер тапкыр физик тәрбия саф һавада үткәрелә.

Мәктәпкә хәзерлек төркемендә шөгыль озынлыгы - 30 минут, шөгыльләр арасында 10 минутлык ял. Көн дәвамында 3 шөгыль, атнага бер тапкыр 4 шөгыль - физик тәрбия саф һавада үткәрелә. Барлык төркемнәрдә дә шөгыльләр көннең беренче яртысында уздырыла. Балаларның яшьләренә карап, төркемнәр буенча физкультминуткалар оештырыла.

Шөгыльләр челтәрен төзегәндә эшчәнлекне төрләндерү принципы күздә тотыла. Һәр төркемдә көн саен физик тәрбия яки музыка тәрбиясе шөгыльләре бар. Атнаның беренче көннәрендә балаларга үзләштерү авыррак булган фәннәр буенча шөгыльләр оештырыла.

Балаларның белем дәрәҗәсен ачыклау максатыннан ел башында һәм ел барышында ике мәртәбә диагностика үткәрелә. Нәтиҗәләр буенча балаларның үсешен күрсәткән мониторинг төзелә.

Балалар бакчасында тәрбия шөгыльләнү вакыты -5 көнлек тәрбия – укыту атнасы, уку елы дәвамлыгы - 37 атнаны тәшкил итә.

Балалар бакчасында уңайлы санитария –гигиена шартлары тудырылган, көндәлек режим үтәлә; һәр баланы шәхес итеп тәрбияләү максатында аерым

кайгыртучанлык күрсәтелә, тиешенчә тукландыру, һәр көн саф һавада булулар оештырыла.

Балалар белән ел дәвамында күңел ачу уеннары һәм бәйрәмнәр уздырыла. Балалар үз-үзләрен тыныч, шат күңелле, өлкәннәр тарафыннан якланган итеп тойсыннар өчен, төркемдә һәм балалар бакчасында уңай эмоциональ шартлар тудырылган.

## ПЕДАГОГИК КОЛЛЕКТИВ

Учреждение, Россия Федерациясенең белем һәм тәрбия бирү системасы юнәлешләре буенча куелган максат һәм бурычларны заман таләпләренә туры китереп чишә алырлык тотрыклы, белемле укытучылар һәм тәрбиячеләр белән тәэмин ителгән.

Учреждениедә 5 педагог: 3 укытучы+1 директор һәм 1 тәрбияче эшли.

Педагогик коллектив һәм администрация эшенең мөһим юнәлеше булып укытучы һәм тәрбиячеләрнең педагогик белемнәрен квалификация күтәрү курсларында һәм аттестация үтү юлы белән арттыру тора. Моның өчен педагоглар даими рәвештә квалификация күтәрү курсларында булалар, аттестация үтәләр.

Алар арасында:

| | Кеше саны | % |
|---|---|---|
| Югары белемле педагоглар | 4 | 80% |
| Махсус урта белемле педагоглар | 1 | 20 % |
| I квалификацион категорияле | 3 | 60 % |
| I1 квалификацион категорияле | 2 | 40 % |
| 10 елга кадәр эш стажы | - | - |
| 10 елдан 25 елга кадәр эш стажы | 4 | 80 % |
| 25 елдан артык эш стажы | 1 | 20 % |

## УКЫТУ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Тулаем алганда учреждениедә укыту сыйфаты тотрыклы. Эшнең төп күрсәткече - 4 сыйныф чыгарылышы һәм балалар бакчасының мәктәпкәчә әзерлек төркеме.

Мәктәпкәчә әзерлек төркемендә өлгереш 100%, ягъни барлык балалар да программаны үзләштергән, уку сыйфаты 75% .

### 4 сыйныфта укыту сыйфаты нәтиҗәләре

Соңгы өч уку елында 4 сыйныф укучылары белән фәннәр буенча региональ мониторинг үткәрелеп килә. 2015-2016 уку елында 4 сыйныфта

рус теле, математика, татар теле, әйләнә-тирә фәннәреннән региональ мониторинг нәтиҗәләре буенча укучыларның фәннәр буенча уртача - 4 билгесе.

**Укучыларның уку сыйфаты нәтиҗәләре**

| Уку елы | Мәктәп буенча уку сыйфаты | 4 сыйныфта уку сыйфаты |
|---|---|---|
| 2011-2012 | 68% | 80% |
| 2012-2013 | 64% | 57% |
| 2013-2014 | 67% | 75% |
| 2014-2015 | 75% | 50% |
| 2015-2016 | 75% | 100% |
| | | |

Балаларның иҗади сәләтен ачыклау һәм үстерүдә фәннәр буенча үткәрелгән олимпиада һәм аң-белем, зиһен үстерү конкурслары зур әһәмияткә ия.

Укучылар мәктәп, район, өлкә күләмендә үткәрелә торган чараларда: олимпиадалар, конкурслар, уен-конкурсларда, спорт ярышларында катнашалар.

**Фәннәр буенча үткәрелә торган төрле дәрәҗәдәге чараларда катнашу**

| № | Чаралар | Дәрәҗә | Катнашучылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Математика фәне буенча «Кенгуру» уен-конкурсы | Дәүләтара | Укучыларның 100% |
| 2 | «Русский медвежонок» уен-конкурсы | Федераль | Укучыларның 100% |
| 3 | «Английский бульдог» уен-конкурсы | Федераль | Укучыларның 100% |
| 4 | «Человек и природа» уен-конкурсы | Федераль | Укучыларның 100% |
| 5 | Татар теле буенча “Зирәк тиен” уен-конкурсы | Региональ | Укучыларның 100% |

## УЧРЕЖДЕНИЕДӘ ТӘРБИЯ ЭШЕ

Балаларны, педагогларны бергә туплау, шулай ук бала шәхесен төрле яклап үстерү һәм җәмгыятьнең үзгәрешчән шартларына җайлашуга ярдәм итү максатыннан, педагоглар коллективы укыту һәм тәрбия эшендә яңа алымнар куллана.

Тәрбия эшенең төп максаты булып иректе, кешелекле, мөстәкыйль, ныклы белемле, иҗади эшкә әзер һәм әхлаклы шәхес тәрбияләү тора.

Әлеге максатка ирешү өчен педагоглар алдында түбәндәге бурычлар тора:

- тирә-юньдәге кешеләргә, вакыйгаларга сабырлык, түзеп торучанлык тәрбияләү (толерантность);
- балаларга әхлак тәрбиясе, патриотик тәрбия бирү;
- балалар белән сәламәтләндерү эшләре алып бару, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү;
- мәктәптә һәр баланың сәләтен ачыклауга юнәлтелгән уңай психологик шартлар булдыру;
- балаларның эшчәнлеген активлаштыру;
- коллективларда тәрбия эшен үстерү;
- гаилә тәрбиясен үстерү.

Мәктәптә педагогларның тәрбия эше 3 яссылыкта тормышка ашырыла: укыту барышында, дәрестән тыш эшчәнлектә, мәктәптән тыш эшчәнлектә.

Дәрестән тыш эшчәнлек ике өлешкә бүленә: сыйныф белән эшчәнлек һәм учреждение күләмендәге эшчәнлек. Балаларның иҗади сәләтләрен үстерүгә зур игътибар бирелә. Учреждение күләмендә даими үткәрелә торган бәйрәмнәр белән бергә төрле темаларга карата кичәләр, рәсем һәм сочинение конкурслары, КВНнар, очрашулар, курчак театрлары, әкиятләрне сәхнәләштерү, викториналар, күңелле стартлар, спорт ярышлары һәм бәйрәмнәре уңышлы үткәрелеп килә.

Тәрбия эшен алып баруда иң мөһим чараларның берсе булып элеккечә сыйныф сәгатьләре кала. Сыйныф сәгатьләре укытучы белән балаларның аралашуында төп чара булып тора. Моннан тыш табигатькә чыгу, бергәләшеп башкарылган эшләр, учреждение күләмендәге чараларга әзерлек, өмәләр коллективны берләштерүгә уңай йогынты ясый.

Бергә эшләгән иҗади эшләр ата-аналар коллективын да берләштерүгә китерә. Әти-әниләр үзләре үк укытучы һәм тәрбияче ярдәмчесенә әйләнәләр. Төрле чаралар үткәрүдә үз тәкъдимнәрен кертәләр, үзләре үк шул чараларда катнашалар. Бу уку елында әти-әниләр катнашында торле мероприятияләр оештырылды.

Патриотик тәрбия бирү – әйдәп баручы юнәлеш булып кала. Аның максаты булып, гражданлык позициясен формалаштыру, Туган илебез белән горурлану хисе, Бөек Ватан сугышы ветераннарына хөрмәт тәрбияләү тора. Мәктәптә батырлык дәресләре, сугыш ветераннарын искә алу, Бөек Ватан сугышына багышланган рәсем күргәзмәләре оештырыла.

Югарыда санап кителгән бурычларны чишүдәге системалылык тәрбия эшен үстерү, мәктәп традицияләрен ныгытуга китерә.

Югары нәтиҗәләргә ирешү өчен, укыту - тәрбия эшен оештыруда ата-аналар арасыннан ярдәмчеләр булу бик мөһим. Һәм без бу максатка ирештек. Ата-аналар һәм педагоглар коллективы күп еллар дәвамында үзара тыгыз элемтәдә эшли. Ата-аналар комитеты да һәм Белем учреждениесе Советы да учреждение эшчәнлеген үстерү өстендә эшли. Утырышларда учреждение күләмендә үткәрелә торган чаралар турында сөйләшүләр алып барыла һәм шул чараларда алар үзләре үк актив катнашалар.

## БАЛАЛАРНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕГЕ ТОРЫШЫ, СӘЛАМӘТЛЕКЛӘРЕН САКЛАУ ҺӘМ НЫГЫТУ

**Укучыларның сәламәтлек төркемнәре буенча бүленеше (2015)**

| Балалар | Саны | Сәламәтлек төркемнәре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | I | II | III | IV |
| Укучылар | 9 | 1 | 8 | - | - |
| Мәктәпкәчә балалар | 12 | 2 | 8 | - | - |

**Укучыларның физкультура төркемнәре буенча бүленеше**

| Балалар | Саны | Физкультура төркемнәре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | төп | әзерлек | махсус | азат ителүчеләр |
| Укучылар | 9 | 9 | - | | - |

Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту максатыннан медицина тикшерүләре, диспансеризация һәм сәламәтлек дәрәҗәсен билгеләү диагностикалары үткәрелә. Уку елы барышында һәр чирек Сәламәтлек көннәре үткәрелә.

Учреждениедә санитар-гигиена таләпләре үтәлә. ФАП фельдшеры белән тыгыз элемтә саклана. Фельдшер профилактик темаларга лекция һәм әңгәмәләр үткәрә, балаларның сәламәтлеген күзәтә һәм медицина ярдәмен күрсәтә. Соңгы өч уку елында балалар арасында имгәнү очраклары теркәлмәгән.

Педагогик коллектив сәламәт шәхес тәрбияләү өстендә эшли. Учреждениедә сәламәтлек һәм иминлекне саклауның төп максаты - балаларда сәламәт яшәешкә омтылыш, сәламәтлекнең иң кирәкле байлык булуына төшендерү.

## ИМИНЛЕКНЕ ТӘЭМИН ИТҮ

Балаларның һәм хезмәткәрләрнең иминлеген тәэмин итү максатыннан учреждениедә янгынны хәбәр итү чаралары каралган: сигнализация һәм янгын сүндерү җайланмалары урнаштырылган. Янгын булган очракта ( алла сакласын) су алу өчен ашханә кырыенда урнашкан стационар җайланма (гидрант), үзәк янгын бүлегенә хәбәр итүче төймә (кнопка тревожной сигнализации) бар. Мәктәпкә керә торган зур капкага кадәр таш юл быел 2016 елны салынды.

Янгын чыгу очрагына каралган эвакуация планы ГОСТ Р.2.12.143-2002 ППБ 01-03.п3 туры килә. Эвакуация юлларын аңлатучы инструкция белән учреждениенең барлык балалары һәм хезмәткәрләре таныштырылган.

Учреждение зданиесендә 4 эвакуация юлы каралган. Мәктәптә тәүлек буе сак оештырылган: көндез-дежур торучы кизү, төнлә-каравылчылар.

Хезмәт саклау буенча тиешле документлар, куркынычсызлык паспорты эшләнгән. Учреждение администрациясе тарафыннан балаларның иминлеген саклауга өстенлек бирелә.

Иминлеккә өйрәтү йөзеннән түбәндәге чаралар үткәрелә:

1. «Тревога» сигналы буенча эвакуациягә өйрәнүләр.
2. Тормыш иминлеге нигезләре буенча сыйныф сәгатьләре.
3. Беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча практик эшләр.
4. Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү һәм ныгыту максатыннан уку елы дәвамында төрле тәрбия чаралары үткәрелә.

## ЭКОНОМИК ЭШЧӘНЛЕК

Учреждениене финанс яктан тәэмин итү түбәндәге юллар белән башкарыла:

- Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы бюджеты;
- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы кануннары карары нигезендә билгеләнгән күләмдә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджеты хисабына;
- эшкуарлар һәм башка табыш китерүчеләр (ата-аналар һәм ирекле ярдәм итүчеләр) хисабына.

2016 елда һәр бала өчен бүлеп бирелгән бюджет акчалары балалар бакчасы һәм мәктәптә алып барыла торган уку-укыту программаларын тормышка ашыру, педагогларның хезмәт хакын түләү, коммуналь уңайлыкларны түләүгә, килешүләр төзүгә тотылды.

## ЧИШЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ ТӨП ПРОБЛЕМАЛАР

Соңгы 3 елда ирешелгән уңышлар дип түбәндәгеләрне санарга була:

- уку-укыту һәм тәрбия сыйфатының тотрыклылыгы (педагогларның укыту дәрәҗәсе, укучыларның уку сыйфаты);

- белем бирүнең яңа технологияләре һәм методларын куллану;

- олимпиадалар, конкурсларда катнашып балаларның сәләтен үстерүгә уңай шартлар тудыру.

-Мәктәп ягында балаларга һәм укытучыларга җылы туалет булдыру.

-тирә-яктагы коймаларны яңарту.

-яңа спорт мәйданчыгы булдыру.

**2016-2017 уку елына бурычлар**

**1. Дәүләт федераль укыту стандартлары буенча эшләү.**

- ✓ 1-4 сыйныфларда укытуны дәүләт федераль укыту стандартының эшчәнлек алымын кулланып “Перспектива” укыту-методик комплекты ярдәмендә алып бару. Мәктәпкәчә төркемдә уку-укыту эшчәнлеге М.А.Васильева программасы буенча дәүләт федераль укыту таләпләрен истә тотып алып бару.
- ✓ Балаларның сыйныфтан тыш һәм дәрестән тыш эшчәнлеген төрлеләндерү һәм эчтәлегенең сыйфатын күтәрү.
- ✓ Уку-укыту эшчәнлегендә кабинетлардагы яңа укыту җиһазларын киң куллану.
- ✓ Тәрбия эшчәнлеген дәүләт федераль укыту стандартларына һәм дәүләт федераль укыту таләпләренә туры китереп алып бару.
- ✓ Заманча тәрбия технологияләрен кулланып тәрбиячеләрнең һәм сыйныф җитәкчеләренең эш сыйфатын күтәрү.

**2. Балаларның уку эшчәнлеген активлаштыру.**

- ✓ Балаларның активлылыгын һәм иҗади сәләтләрен үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру:

- мәктәп буенча фән олимпиадалары, интеллектуаль һәм иҗади конкурслар үткәрү;

- укучыларның муниципаль олимпиадаларда һәм конкурсларда катнашуларын дәвам итү;

- балаларның уңышларын барлап бару максатыннан укучы портфолиоларын тулыландыру;

- мәктәпкәчә уку-укыту эшчәнлегендә проект технологиясен кертү;

- мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп балаларының иҗади һәм интеллектуаль эшчәнлегендә бердәм эшләүләренә ирешү.

**3. Мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп балаларының сәламәтлеге.**

- ✓ Балалар бакчасында тәрбияләнүче һәм 1-4 сыйныф укучыларының сәламәтлеген кайгырту һәм күзәтүне дәвам итү.
- ✓ 1-4 сыйныф укучыларының Сәламәтлек паспортларын алып баруны дәвам итү.
- ✓ Балаларда сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләү өстендә эшне дәвам итәргә.